# Нурчыклар

*Буа районы “Кояшкай” балалар бакчасы гәҗите*

**№5 Гыйнвар,2021 ел**





Бүгенге санда

2021
Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы



«Без милли телләр һәм мәдәниятләр үсеше өчен шартлар тудырырга тиеш. Рус, чуваш, удмурт, мордва, марилар һәм башкалар. Бу мәсьәләгә зур игътибар биреп, киләсе елны Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан итәргә тәкъдим итәм…

Телебез — рухи яктан берләштерүче зур көч. Татар телен саклау һәм үстерү буенча комиссиягә дә зур өметләр баглыйбыз. Бу эштә барлык хакимият органнары һәм иҗтимагый оешмалар катнашырга тиеш. Туган тел — үз халкың белән нечкә элемтә. Без аны саклап калу өчен барысын эшләячәкбез. Бу алдагы буын алдында әхлакый бурыч», — диде Президентыбыз Рөстәм Нургали улы Миңнеханов.

Дөньяда бик күп телләр бар, ләкин һәр кешегә иң матур һәм иң яраткан тел – ул Туган тел. Күп кешеләр башка телләрне дә яхшы беләләр, әмма туган тел барыбер аларның һәрберсе өчен иң кадерле. Туган тел аша без дөнья белән танышабыз. Ул белемнең һәм акылның саклаучысы. Туган үскән илнең якынлыгын, Ватанның газизлеген тоярга да безгә туган тел ярдәм итә. Туган тел хезмәт белән бергәкешене үстерә, аңа Ватанның тарихын белергә, милли сәнгатен аңларга, яратырга ярдәм итә.

2021 ел Татарстан Республикасында Туган телләрне саклау һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителде. Төп максат-Татарстан Республикасында яшәүче барлык халыкларның туган телләрен, мәдәниятләрен, традицияләрен саклау,милли бердәмлекне ныгыту.

***Балалар бакчасы мөдире Э.З.Әбүзәрова***

# Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын ачу тантанасы





21 января, в нашем детском саду состоялось торжественное открытие Года родного языка и народного единства. У каждого народа свой язык, свои традиции.Мы должны его сохранить и передать следующему поколению. Праздник прошел очень весело.Дети пели на трех языках,читали стихи, играли в национальные игры. Праздник завершился песней о дружбе.





Һәр халыкның үз теле, традицияләре бар.Без аны сакларга,киләсе буынга тапшырырга тиешбез. Шул максат белән, 21 гыйнвар көнне безнең бакчабызда Туган телләр һәмхалыклар бердәмлеге елын ачу бәйрәме узды. Бәйрәм бик күңелле узды.Балаларөч телдә җырладылар, шигырьләр сөйләделәр,милли уеннар уйнадылар.Бәйрәм дуслык турында җыр белән тәмамлады.

# Куян белән кышкы урманга сәяхәт

27 гыйнвар көнне безнең балалар бакчасында "Куян белән кышкы урманга сәяхәт"дигән икенче кече яшьтәге балалар төркемдә физкультура дәресен карау булып узды. Дәреснең максаты балаларның физик һәм психик сәламәтлеген ныгыту, хәрәкәткә ихтыяҗ формалаштыру, хәрәкәт тәҗрибәсен туплауга ярдәм итү иде.



# Сәламәт тәндә – сәламәт рух!

27 гыйнвар көнне безнең бакчабызда "Сәламәт тәндә - сәламәт рух!" исемле ачык шөгыль узды. Балаларспорт уеннары уйнадылар, эстафетада ярыштылар.Һәм, әлбәттә, спорт күнегүләренә кызыксыну һәм кәеф тудыручы әкият геройлары - әкият персонажларыннан башка узмады.Шөгыль кызыклы үтте.Балаларга бик ошады.







# Туган телем – серле тел

## Туган тел



*И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!*
*Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.*
*Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,*
*Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.*
*И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең,*
*Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.*
*И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:*
*Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!*

*Габдулла Тукай*

## Яхшы бел



*Татарча да яхшы бел,Бу телдә рух байлыгын*
*Русча да яхшы бел, һәм йөрәк кайнарлыгын.*
*Икесе дә безнең өчен Җырлаган бу телдә безгә*
*Иң кирәкле затлы тел.Сөекле Тукай моңын...*
*Татарчасы - туган тел, Тел кешене дус итә,*
*Безгә газиз булган тел.Бер-берсенә беркетә.*
*Атаң-анаң, әби-бабаң, Бел, балам, син рус телен*
*Сине сөя торган тел. Һәм онытма үз телең!*



*Шәйхи Маннур*

## Туган телем



*Дөньяда иң-иң матур ил,Туган телемдә сөйләшеп,*
*Ул – минем туган илем.Яшим мин туган илдә.*
*Дөньяда иң-иң матур тел,“Туган ил” сүзне дә*
*Ул – минем туган телем.Әйтәм мин туган телдә.*
*"Балам!" - диеп туган телдәИң изге хисләремне мин*
*Эндәшә миңа әткәм.Туган илдә аңлатам.*
*"Әнием!" - дип, әнкәемәШуңа күрә туган телне*
*Мин туган телдә әйтәм.Хөрмәтлим мин, яратам.*

*Энҗе Мөэминова*

## В день солнечный июльский

*В день солнечный июльский,Иду тропинкой узкой-*
*Цветы, цветы вокругДеревья до небес!*
*Красив язык мой русский,Могуч язык мой русский*
*Как этот летний луг.Как этот русский лес!*

*И в радости и в грусти –*
*Он всякий час со мной.*
*Родной язык мой русский,*
*Как Родина роднойА.Шибаев*



# 10 аерманы тап





«Нурчыклар» гәҗитен
гамәлгә куючы:
Татарстан Республикасы
Буа шәһәренең катнаш
төрдәге “Кояшкай” балалар
бакчасы” муниципаль бюджет
учреждениесе

Редколлегия әгъзалары:
Гыйниятуллина Д.Р.

Безнең адрес:
422430,Буа шәһәре,
Арефьева урамы, 13 йорт

Тел. (843)743-13-09
E-mail: colnush-bua@mail.ru